ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 сентябрь 2015 ел № 5394

Башкарма комитетның 2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.34 маддәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы, «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законнар, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләти хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче карары (Башкарма комитетның 2013 елның 10 июнендәге 3487 нче, 2013 елның 7 августындагы 4712 нче, 2013 елның 22 октябрендәге 6360 нчы, 2014 елның 25 февралендәге 1139 нчы, 2014 елның 7 маендагы 2654 нче, 2014 елның 13 маендагы 2708 нче, 2014 елның 25 июлендәге 4366 нчы, 2015 елның 4 мартындагы 1359 нчы, 2015 елның 31 июлендәге 4337 нче карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, аны түбәндәге эчтәлектәге 81 пункт белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә.

«81. Муниципаль милектә урнашкан җирләрне яки җир кишәрлеген файдалануга рөхсәт бирү.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Д.В. Щербага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

Р.Ә. Абдуллин